## Исәнбай мәктәбенең иң тәүге мөгалимнәре Мөкарәммә белән Хәбибулла Насыйбуллиннар



**1900 нче ел**

1897 нче елда Исәнбай авылында “рус-башкорт училищесы” дигән дүртьеллык башлангыч мәктәп ачыла. Казанда укытучылар мәктәбен тәмамлаган Насыйбуллин Хәбибулла Фәтхулла улы укытучы булып килә. Төскә-биткә чибәр, мыеклы, килешле гәүдәле, өстенә кара костюм, башына түбәтәй, аякларына кара ботинка кигән, йомшак кына сөйләүче укытучыны авыл халкы бик ошата.

Барча малай-шалайны кызыктырып, Хәбибулла Сарапулдан ачылмалы парталар, кара такта, глобус һәм тагын әллә никадәрле вак-төяк төяп кайта. Мәктәпнең үзенең бинасы булмый, сәүдәгәр Әхмәтвәли Тютиев йортын файдаланалар.

## Исәнбай мәктәбенең иң тәүге мөгалимнәре Солтангазиз Абдуллин һәм Шәмсекамәр

1903 нче елның 1нче декабрендә Хәбибулла белән Мөкаррәмә авылдан китәләр. Алар урынына Мөкаррәмәнең бертуган абыйсы Солтангазиз Абдуллин атлы егет укытырга килә. Ул да Казандагы мөгаллимнәр мәктәбен тәмамлый. Әгерҗе җиренә килеп төшүгә, Тирсәдәге Шәмсекамәр атлы кыз белән танышып ала. 1904 нче елда Исәнбайда туй ясыйлар. Солтан малайларны укытса, Шәмсекамәр кызлар укытучысы була. Мәктәптә укучы балалар саны 140 ка якынлаша.



1915 нче елда Солтанны Беренче Бөтендөнья сугышына, герман фронтына алып китәләр. Ләкин бер ел чамасы вакыт үтүгә үк, ул кабат Исәнбайга кайта, Шәмсекамәре белән бергә мәктәптә укытуын дәвам итә.